Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 2 (2)

13 октябрь 2011 ел

## • Ике авыз сүз

10 октябрь көнне университет ректоратының чираттагы утырышы узды. Илшат Гафуров алдагы шимбәдә Физик-химик медицина фәнни-тикшеренү институты директоры Вадим Говорун һәм Стратегик башлангычлар агентлыгы җитәкчесе Андрей Никитин белән булган очрашулар турында сөйләде. Шулай ук институт һәм аерым бүлекләргә якын арада үсеш программаларын тәкъдим итәргә кирәклекне искә төшерде, кадрлар мәсьәләсенә бәйле сорауларның уңай чишелешен тәэмин итү максатыннан, махсус комиссия төзү турында тәкъдим булуын әйтте.

Укыту-методик идарә җитәкчесе Ольга Тимофеева балл-рейтинг системасы, укыту-методик комплексы, курс эшләрен язу һәм яклау регламентларының яңа редакциясе белән таныштырды. Шулай ук сәбәпле дәрес калдыручы актив студентлар мәсьәләсе дә игътибардан читтә калмады. Ректор әлеге регламент кысаларында бу сорауны да уңай хәл итәргә кирәклекне искәртте.

Курс һәм диплом эшләрен язу-яклауга бәйле өлештә аеруча игътибарның плагиатка каршы көрәшкә юнәлдерелергә тиешлеге билгеләп үтелде. КФУ президенты М.Сәлахов студентларның курс һәм диплом эшләрен туплаган электрон база булдыруның мөһимлегенә аерым тукталды. Иң уңышлыларын, бар кеше куллана алсын өчен, сайтка урнаштыру мөмкинлеген табу мәсьәләсе дә күтәрелде.

Утырышта «Математикмодельләштерү һәм кара алтын ятмаларын билгеләүдә мәгълүмати технологияләр» фәнни-белем бирү үзәгенең нигезләмәсе каралды, КФУның Чаллы филиалы директоры Анатолий Макаров укыту-лаборатория корпусының төзелешенә бәйле эшләрнең торышы белән таныштырды.

• • • •

Казан федераль университеты октябрь аеннан башлап «Татарстан» ДТРК һәм ТРның Хәйрия эшләре советы белән берлектә «Өйгә таба юл» дип аталган хәйрия проектында катнаша. Проектның максаты – ятим балаларга ярдәм итү. Студентлар энтузиазм һәм зур кызыксыну белән эшкә тотындылар.

• • • •

7 октябрь көнне 2011-2012 уку елында Потанин стипендиясен алачак 20 студентның исеме игълан ителде. Бу федераль стипендияләр программасы 2000 елдан иң зур белем бирү проекты буларак эшләп килә. Аның максаты – яхшы укучы студентларның мөмкинлекләрен киңәйтү, һөнәри һәм шәхси үсешләрендә ярдәм итү. Быел стипендиянең күләме 4000 сум булачак.

• • • •

10 октябрьдә университетның Үсеш программасын тормышка ашыру кысаларында АКШ халыкара сәүдә мөнәсәбәтләре бүлеге җитәкчесе, Олбани дәүләт университеты (Нью-Йорк штаты) профессоры, доктор Джеральд Шей килде. Ул икътисад факультетында белем алучы магистрларга лекцияләр укыды.

• • • •

Бүген, ягъни 13 октябрь «Совет чорыннан соң рухи һәм сәяси культура традицияләре һәм яңалыклар: этноконфессиональ өлкәләрнең үзара йогынтысы» дигән темага Казан федераль университеты ТР Фәннәр Академиясе белән берлектә оештырган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үз эшен башлап җибәрде. Биш секциягә бүленеп эшләгән әлеге конференциядә «Хәзерге Россиядә дини яңарыш феномены», «Россия мөселманнары арасында толерантлык моделен эзләү», «Россия җәмгыятендә этноконфессиональ мөнәсәбәтләрне өйрәнүнең методологик проблемалары» һ.б. җитди мәсьәләләр каралачак.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы.

# «Кояш иле» кунаклары

**Рамил ХАННАНОВ**

Университет 11 октябрь көнне үзендә Япония кунакларын кабул итте. Япониянең Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле Тикахито Харада җитәкчелегендәге делегация әүвәл Казан университеты тарихы музеенда, аннары сирәк язмалар һәм китаплар бүлегендә булды.

Бераздан кунаклар КФУ президенты М.Сәлахов җитәкчелегендәге университет вәкилләре төркеме белән очрашты. Физика институты директоры Альберт Аганов һәм биология һәм туфракны өйрәнү факультеты деканы Рушан Сабиров КФУ һәм Япония югары уку йортлары арасындагы хезмәттәшлек турында сөйләделәр. А.Аганов белдергәнчә, физика институты Япониянең эре фәнни-тикшеренү үзәге булган RIKEN физик-химик тикшеренүләр институты белән тыгыз элемтәдә эшчәнлек алып бара. Ә биология һәм туфракны өйрәнү факультеты исә диңгез һәм космик биология өлкәләре буенча хезмәттәшлекне арттырган.

Тикахито Харада Япония вузлары һәм КФУ арасында тыгыз элемтәләр булуга күпмедер гаҗәпләнде дә. Ул: «Икеяклы мөнәсәбәтләрне тагын да көчәйтү өчен, әлбәттә, фән-мәгариф өлкәсендә тыгыз бәйләнешта булырга кирәк», – диде. Вәкил һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер икәнлеген дә әйтте. Казан федераль университетының Мактаулы кунаклар китабына исә: «Сезнең мәнә дигән уку йортыгызда булуыма чиксез шатмын. КФУ белән Япониянең академик даирәләре арасында күперләр нык булыр дип уйлыйм», – дип язып калдырды.

*Рәсемдә: Япония кунаклары КФУның тышкы элемтәләр буенча проректоры Линар Латыйпов белән.*

## • Алар бездә укыган

# Ул үзе дә салават күпере!

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

*Без барыбер бу заманның*
*Бер сөекле затлары.*

Шулай дип яза ул үзенең «Битаман» дигән шигырендә. Язып кына калмый, ә 50 яшь тулу уңаеннан үткәрелгән кичәдә дә нәкъ менә шул сүзләргә иҗат ителгән җыр белән башлап җибәрә танылган язучы, шагыйрь, драматург һәм җәмәгать эшлеклесе, А.Алиш, Ф.Хөсни, Г.Исхакый һәм М.Җәлил исемендәге премияләр иясе, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зиннур ХӨСНИЯР.



Зиннур Хөснияр иҗаты минем өчен артык таныш түгел иде. Аны аз белүемә карамастан, зур бер бәйрәмгә барган кебек килдем кичәгә. Чәчәк бәйләмнәрен күтәргән халык агыла да агыла...

**Ахыры 2нче биттә.**

**Милли мирас**

# Татарстанны ЮНЕСКО көтә

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

6 октябрь көнне университетта «Бүгенге дөньяда мәдәни мирас: тәҗрибәләр, проблемалар һәм аны саклау перспективалары» дигән исем астында Халыкара музейлар форумының пленар утырышы булды.



Алия Галимуллина фотосы.

Утырышта мактаулы кунаклар - мәдәни байлыкларны саклау һәм төзекләндерүнең халыкара ICCKOM тикшерену үзәге генераль директоры Мөнир Бушенаки, РФның ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе җаваплы сәркәтибе Григорий Орджоникидзе, Россиядә ИКОМОС милли комитет президенты Игорь Маковецкий, Дәүләт тарих музее президенты Александр Шкурко, Халыкара ЮНЕСКО культура һәм табигать мирасы үзәге белгече Александро Бальзамо, Мәскәүдәге ЮНЕСКО кафедрасының инженер-киңәшчесе, эксперт Клод Госслен һ.б. белән бергә бу өлкәдә эшчәнлек алып баручы һәм белем алучы студентлар да катнашты.

И.Гафуров, чараны ачып, катнашучыларны сәламләгәч, уку йортында күп еллардан бирле сакланып килгән традицияләр турында сөйләде. Университет оешкан елларда ук ачылган «Сирәк әйберләр музее»на ул аерым тукталды, КФУның мәдәни мирасны саклауда зур үзәк булуын искәртте.

Әүвәл форумда катнашучыларны Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе, ТР тарихи һәйкәлләрен һәм мәдәниятен яңарту фондының кайгыртучылар советы рәисе Минтимер Шәймиев сәламләде. Ул Казан федераль университетының кешелек дөньясында бик мөһим юнәлешне саклавы – рухи торышны кайгырткан уку йортлары арасында әйдәп баручы булуы өчен шатлануын яшермәде. Объектив сәбәпләр аркасында һаман икенче планга калып килгән һәм менә хәзер башланып киткән эшнең дәвамчылары булган студентларның Музейлар форумында катнашуын аерым билгеләп үтте. «Бу эш белән яшәргә, аны белергә кирәк, үткәнне өйрәнми торып, киләчәк юк», – диде ул. Шулай ук бу өлкәдә зур тырышлык куйган галимнәргә, археологларга, тарихчыларга рәхмәтен белдерде. М.Шәймиев ЮНЕСКО экспертларының үз эшләрен мавыгып, яратып башкаруларына басым ясады. «Без бөтен дөнья һәм Россия күләмендә мәдәни мирасны, тарихи объектларны саклау өлкәсендә эшләүче институтларны фәнни яктан тәэмин итәргә тиешбез. Бу бик мөһим», – дип тәмамлады ул чыгышын.

Мөнир Бушенаки, Минтимер Шәймиевнең чыгышын хуплап: «Җәмгыять өчен иң зур байлык – рухи байлык. Хәзерге глобальләшү, матди байлык өстенлек иткән дәвердә күп проблемалар рухи идеяләр онытылып барганлыктан килеп чыга», – диде. Хәтерләсәгез, ул, беренче мәртәбә Казанга 2001 елда килеп, Татарстанның беренче президентына Казан Кремлен ЮНЕСКО тарафыннан саклана торган мәдәни мирас итеп тану турындагы сертификат тапшырган иде. М.Бушенаки Зөя утрау-шәһәрчегендәге зур үзгәрешләргә соклануын әйтте. «Безнең килүебезнең максаты – Зөянең кайсы элементлары дөньяви, мәдәни һәм рухи кыйммәткә ия булуын, шулай ук Россия, Татарстан экспертлары белән Болгарның архитектур һәм тарихи үзенчәлеген ачыклау», – диде ул. М.Бушенаки бу өлкәдә 40 ел эшләү дәверендә бик күп тарихи урыннарда булган. Татарстанда яшәүче милләтләр арасындагы үзара мөнәсәбәт, толерантлык ЮНЕСКОны шатландыруын белдерде.

Григорий Орджоникидзе, үз чиратында, университет галимнәренә һәм укытучыларына бу зур һәм әһәмиятле теманы күтәргәннәре, форумны әзерләүләре өчен рәхмәтен белдерде. Ул Минтимер Шәймиевнең Россия Федерациясенең ЮНЕСКО эшләре буенча комиссиясе составында күп еллар дәвамындагы нәтиҗәле эшчәнлеген билгеләп үтте. «Татарстан Республикасында мәдәнияткә һәм милли мираска булган игътибар Россия өчен үрнәк булып тора», – диде Г.Орджоникидзе.

**Алар бездә укыган**

# Ул үзе дә салават күпере!

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

*Башы 1нче биттә.*



Юбиляр язучы Мәдинә Маликова белән.



Зиннур Хөсниярны Алмаз Хәмзин халык белән бергә котлый.

Димәк, әдипнең дуслары, туганнары күп, аны яраталар дип уйлап куйдым мин. Пәрдә ачылгач, сәхнәдә бүтән иҗат кичәләрендә була торган бизәлешнең юклыгына аптырап калдым. Монда никтер юбиляр утырачак өстәл, затлы кәнәфи дә күренми, ә кечкенә генә бер табигать почмагы. Мөгаен, табигать кочагында туып, тугач та «саз малае» исемен алып үскәнгә, әлеге күренеш якындыр әдип йөрәгенә. Ә үзе ул залда, дуслары арасында урын алган иде. Башкалар ничектер, мин үзем сәхнә читендәге агачны әдипнең үзе белән тиңләп утырдым. Нык, тамырлары тирән, яфраклары куе, җимешләре мул агач. Кичәнең сәбәпчесе булган шәхесне шундый агач белән тиңләп була. Агач янында кечкенә генә ике авыл өе. Тәрәзәләрендә ут яна. Бу, әлбәттә, әдипнең туган нигезе. Ул бүген бәхетле, чөнки аның әти-әнисе исән. Димәк, туган йортта ут яна, аны анда көтәләр. Икәве шушы баһадир егеткә гомер, тәрбия бирсә, апасы Бәрия аның иҗат юлына кереп китүенә сәбәпче була. Мәктәптә начар укуы, шаянлыгы белән танылган малайга яхшы билгеләр бәрабәренә сәгать вәгъдә итә ул. Бу вакыттагы сәгатьле булу хыялы аның тормышын бөтенләй башка якка үзгәртә. Көндәлектәге икеле, өчлеләр югала, егет үҗәтләнеп укырга керешә. Шул чактагы үҗәтлеге аны бүгенге дәрәҗәсенә җиткерә. Ә сәгатьне хәзерге көнгә кадәр көтеп яши Зиннур Хөснияр.

Ул беренче шигырен унбиш яшендә яза. Тел, әдәбият белән кызыксынуы аны КДПИның татар филологиясе һәм тарихы факультетына алып килә. Юбилярны котларга килгән мәдәният министрлыгы вәкиле Кадрия Идрисова аның әнә шул чор тормышына басым ясады. Биредә белем алган студент кыз «Илһам» иҗат түгәрәген җитәкли. Үзеннән соң эстафетаны Зиннур атлы егеткә тапшыра. Егет инде факультетта гына түгел, бөтен институтка «язучы» кушаматы белән танылган була. «Илһам» түгәрәге аның иҗатына җирлек булды, ә иҗаты исә орлык. Бүгенге көндә инде ул үсте, җимеш бирде. Син шушы көнгә кадәр шул вакыттагы «язучы» кушаматыңа тугры калдың», – диде Кадрия ханым.

«Балалар журналында эшләү – зур хезмәт. Күңелең буш булса, сабыйларга нидер биреп булмый», – дип бәяләделәр аны «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыятеннән килгән дуслары. Балаларны яратадыр, яратмаса, үзенең шушы шатлыклы көнендә «Бәләкәй Апуш» конкурсында җиңүчеләрне бүләкләргә чакырып, сөенечен үзенең укучылары белән дә бүлешмәс иде.

> *Зиннур Хөснияр оста прозаик, шагыйрь. Безгә ул кечкенәдән «Салават күпере»нең әтисе буларак та таныш һәм якын. Беренче төсле журналга моннан егерме ел элек нигез сала ул. «Салават күпере» аша балачакка кайтам», – ди үзе дә.*

«Аның пьесалары буенча куелган спектакльләрне дә бөтен җирдә яратып кабул итәләр», – ди «Әкият» курчак театры җитәкчеләре. Алар З.Хөсниярның үзен дә салават күпере белән тиңлиләр. Чыннан да, аның иҗаты күпкырлы һәм якты төсләргә бай. Кичә барышында Хәлим Җәләй, Алмаз Гәрәев һ.б. Камал театры артистлары укыган шигырь-хикәяләр, Илназ Минвәлиев, Булат Нигъмәтуллин, Алмаз Хәмзин җырлаган җырлары аша тамашачы моңа тагын бер кат инанып утырды. Аны котларга күтәрелгән «Сәхнә» журналы редколлегиясе исә моны тагын бер кат исбатлады. Әлеге журналга да нигезне З.Хөснияр салган. Ул бу эшне башлап җибәргән, баш мөхәррир булган. Хәзер исә бу вазифада – Туфан Миңнуллин. «Хәзерге көндә газета-журналларны ябучылар күп, ә менә ачучылар сирәк. Без «Сәхнә»дә Зиннурның традицияләрен дәвам итеп, ул туплаган коллектив белән дус-тату эшлибез», – ди Туфан ага. З.Хөсниярның әле «Таһир-Зөһрә», «Әбугалисина» кебек журналларны гамәлгә куючы икәнен дә әйтү кирәктер.

Котларга килгән 18нче хастаханәнең баш табибы, әдипнең якын дусты Рөстәм Бакиров исә аның депутат ярдәмчесе буларак та зур эшләр башкарганын билгеләп үтте. Танылган хирург З.Хөснияр белән танышканнан соң, иҗат кешеләре арасында еш була башлаган һәм үзе дә шигырь язып алып килгән.

Әйе, дуслары чиксез күп әдипнең, ләкин иң ышанычлысы, күңелен ачып салырдае Бәрия апасының ире Хатмулла җизнәсе Вакказов икән. Ул да кичәдә аның яраткан җырын башкарды.

Туган ягында – Биектауда да онытмыйлар әдипне. «Ул бездә һәрвакытта да көтеп алынган кунак», – диләр район хакимияте җитәкчеләре.

З.Хөснияр юбилей кичәсендә тагын бер куанычлы вакыйганы бәйрәм итте. Аның «Хуш, авылым» романы китап булып басылып чыккан.

Кичә соңында үзе, сәхнәгә күтәрелеп, халыкка шигырьләрен бүләк итте. «Өем бик зур түгел иде, шуңа пожары да зур булмады инде, дип әйткән ди бер авыл карты», – дип йомгак ясап куйды ул.

• Яңа дәреслек

# Беренче сыйныфта – «Сингапур моделе»

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Егерменче гасырның 70нче еллары… Әле унбиш яшен генә тутырган авыл кызлары, зур сынаулар үтеп, Арча педагогия училищесына укырга керәләр. Гөлсинә белән Фәридә – укытучы һәм өлкән пионервожатый, ә Миләүшә укытучылар хәзерли торган төркемгә эләгә.



Фәридә Хәсәнова

Ул вакытта студентларның теләген сорап тору булмый. Өлкән пионервожатый һөнәре ул кешедән бик нык оешканлыкны, җитәкчелек һәм алдан планлаштыру сәләтенә ия булуны, оста уйлап табучы, идеяләр бирә алучы, гомумән, үз артыннан башкаларны ияртә белүче кеше сыйфатлары булуны таләп итә.

Ә башлангыч мәктәп укытучысын һәркем тыныч, сабыр, әни кеше һәм психолог итеп хәтерендә калдыра. Бу кызларның 1971 елда ук педагоглык юлына кереп китүен исәпкә алсак, бүген бу вакыйгага 40 ел вакыт үткән булып чыга. Фәридә, Гөлсинә, Миләүшәләр – бүгенге көндә татар мәгарифенең танылган шәхесләре. Куйган максатларына ирешеп, зур үрләр яулаган Мөгаллимәләр бүгенге көндә бик зур проект өстендә эшли.

«Перспектив башлангыч мәктәп» укыту-методик комплекты яңа Федераль дәүләт белем стандартларын һәм базис укыту планын тормышка ашыручы дәреслекләр җыелмасы. Ф.Ф.Хәсәнова, М.Я.Гарифуллина, Ә.Г.Мөхәммәтҗанова, Г.М.Сафиуллиналар төзегән «Әдәби уку» дәреслеге шушы таләпләргә җавап бирә.

Без бу яңалык турында филология фәннәре кандидаты, доцент **Фәридә Фирдәвес кызы ХӘСӘНОВА** белән фикер алыштык.

***– Мондый дәреслек язарга сезне нәрсә мәҗбүр итте?***

– Бала китаптан бизә бара бит. Аларны күбрәк компьютер уеннары, телевизор, Интернет җәлеп итә. Бер сүз белән әйткәндә, татар китабын саклап калу максаты күздә тотылды.

***– Фәридә апа, Сез безне укыткан вакытта һәр язучының, һәр әсәрнең яңалыгына басым ясый идегез. Мин дә Сездән бу дәреслекнең яңалыгы нәрсәдә дип сорыйм әле?***

– Татар баласы башта «Әлифба»дан хәрефләр танырга, иҗекләр кушарга, сүзләр укырга өйрәнде, аннан соң «Туган тел» (соңгы елларда ул башка исемнәр белән дә аталып килende) китабына күчә иде. Әлегә кадәр басылып чыккан дәреслекләрдә әдәби әсәрләр аерым-аерым яшәде. Ә безнең дәреслек (ул беренче тапкыр татар телендә «Әдәби уку» дип атала) гомуми бер интригага корыла: Әминә белән Әмирнең табигатькә сәяхәте рәвешендә тәкъдим ителә, ягъни укытучының җитәкчелек роле балаларның танып белү эшчәнлеге белән бергә бара. Дәреслектә бер сюжет алына һәм ул эзлекле рәвештә үстерелә. Бу сюжет малай белән кызның китап, әсәр, рәсем сәнгате аша тәҗрибә туплавына нигезләнә. Балалар мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт иткән кебек тоела, ягъни аларга укытучы кирәкми дә.

***– Әлеге юнәлешне укытучылар ничек кабул итәр соң?***

– Тышкы яктан гына шулай ул. Укытучы аларны күзәтә, кирәк икән, юнәлеш бирә, әмма үз фикерен көчләп такмый. Соңгы вакытларда мәгарифтә «Сингапур моделе»нә тартылу сизелә. Бу дәреслек әлеге яңалыкка да туры килә, ягъни укытучы балалар белән хезмәттәшлек итә.

***– Бу укытучының җитәкчелек ролен юкка чыгармасмы соң?***

– Дәреслек авторларының өчесе – укытучы. Нәкъ менә шул проблема килеп чыкмасын өчен, алар дәреслекне берничә ел Балтач мәктәпләрендә сынап карадылар. Безнең уебызча, укытучының абруена зыян килмәс.

Тәкъдим ителгән укыту-методик комплекты баланың тормыш тәҗрибәсе, яше генә түгел, үзе яшәгән тирәлекне күзаллау, бәяләү дәрәҗәсе дә. Шәһәр баласы күптөрле мәгълүмат чыганаклары белән чолгап алынган булса, авыл баласы табигать ритмына көйләнгән тирәлектә, эре мәдәни үзәкләрдән читтә яши. Тәҗрибәсе табигать законнарына бәйләнгән. Шәһәр баласы табигатькә авыл укучысы күзаллавы аша бәяләмә бирә, шәһәр, музейлар буйлап авыл баласы белән сәяхәт итә. Дәреслек бала белән аның үз телендә сөйләшүгә юнәлтелә.

***– Дәреслекнең составы нидән гыйбарәт?***

– Ул укыту методик комплекты составына керә, ягъни хрестоматия, эш дәфтәре, электрон дәреслек, мультимедиа дискларыннан тора. Болар өстенә укытучы өчен һәр дәреснең план-конспекты, эш программасы да тәкъдим ителә. Бүгенге көндә һәр дәрестә 2-3 минутлык мультфильм күрсәтеп алу да планлаштырыла. Алар әдәби әсәрнең эчтәлеге белән кызыксындыру өчен эшләнелә. Балаларны яшьтән үк татарга гына хас телбизәкләр белән таныштыру, бигрәк тә шигырь ярату, рәсем сәнгатенә соклану кебек хисләр формалашыруга юнәлтелә. Дәреслектә бер фәндә үзләштерелгән белем һәм күнекмәләрнең икенче фәннәрне өйрәнгәндә файдаланылуы да күзәтелә.

***– Эш дәфтәре була, дидегез. Аның әһәмияте нидә?***


– Мөстәкыйль эш дәфтәрләреннән башка дәреслек белән эшләү мөмкин түгел, чөнки һәр дәрестә дәреслек биремнәре дәфтәр белән эш таләп итә. Шуңа күрә һәр балада дәфтәр булдырырга кирәк. Дәфтәр биремнәре укучының иҗат фантазиясен, эзләп табу эшчәнлеген һәрьяклап үстерү максатын куя, иҗат итү өчен махсус буш урыннар калдырыла, рәсемнәр укучы буярлык эре итеп бирелә (раскраска). Барысын да буяу мәҗбүри түгел; дәреслек биреме, укытучы сайлавы яки укучы теләге буенча буярга мөмкин. Эш дәфтәрләрен әти-әниләр үзләре сатып алырга тиеш була.

***– Дәреслектәге төсле сурәтләр баланың игътибарын башка әйберләргә юнәлдерер дип уйламыйсызмы?***

– Рәссам күргәзмәсендә сәяхәт итеп, I сыйныф укучысы фольклор әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр белән таныша. Аңа автор һәм рәссамның вакыйгаларны тасвирлау алымнарын эзләп табу мөмкинлеге тудырыла. Текст чылбыр буенча укылганда, бала, китап кырында бирелгән сары һәм зәңгәр төсләргә карап, үз чираты җиткәнне белә. Мондый эш алымы баланың игътибарлылыгын үстерә, текстны бербөтен буларак кабул итәргә ярдәм итә.

***– Сез мәктәп укытучысы урынында булсагыз, әлеге китапны төзүчеләргә нинди теләкләр әйтер идегез?***

– Татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укытучыга тулы цикллы ярдәмлекләр күп түгел. Ә башка предметларда алар күптән эшләнде инде. Дөрес, Альберт абый Яхин дәреслекләре, һәр дәрескә укыту ярдәмлекләре бүген дә үз кыйммәтен югалтмый әле. Аннан, соңгы вакытларда рус телле балаларны татар теленә өйрәтүгә зур игътибар бирелә. Безнеңчә, татар баласын ана теле һәм әдәбиятына өйрәтүгә игътибар кимүе күзәтелә. Татар мәктәп-гимназияләрендә атнага берәр сәгать кенә әдәбият укыту – моның ачык дәлиле. Ана телен инглиз теле белән алыштыру бөтенләй «модалы» күренешкә әйләнеп бара. Бу җәһәттән, безнең дәреслекне татар баласына ана теле һәм әдәбиятын өйрәтү буларак кабул итәргә кирәк.




• Сәнгать

# «Зәңгәр шәл» һәм тагын 5 премьера…

**Регина РАЯНОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында иртәгә, ягъни 14 октябрьдә яңа 106 сезон ачыла. Быелгы сезонда тәүге тамаша – Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр» спектакле.

Безне яңа сезонда 6 премьера көтә. 7 ноябрьдә – традиция буенча мәшһүр режиссер Марсель Сәлимҗановның туган көненә багышланган премьера – Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е кабат сәхнәгә кайта. Аны режиссер Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштерә. Булат ролендә – Ирек Кашапов, Мәйсәрәне – Гүзәл Минакова, Ишанны – Әсхәт Хисмәт, Җиһаншаны Минвәли Габдуллин башкарачак. Матбугат конференциясендә билгеләп үтелгәнчә, әлеге спектакль премьерасы – легендар классик пьесаның егерме беренче гасырдагы яңача укылышы. «Зәңгәр шәл» спектакле инде бик күптәннән театрның визит карточкасына әверелде, аның һәр куелышы театр тарихында яңа сәхифә булып тора.

Икенче премьера – Ркаил Зәйдулланың татар кызлары өчен беренче мәдрәсә оештыручы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, хатын-кызлардан беренче мөфти Мөхлисә Бубига багышланган «Үлеп яратты» әсәре буенча куелган спектакль. 2012 елның апрелендә Илгиз Зәйниевнең «Ак чәчәкләр иле һәм Кара көчләр» спектакле куелачак. Театр коллективы, бу спектакльне гаилә белән карау өчен, инновацион технологияләр һәм заманча театраль ысуллар кулланып, искиткеч матур шоу формасында әзерли.

Чираттагы премьера – Карло Гоццины «Хан кызы Турандот» спектакле. Бу – Татарстан-Кытай проекты. Кытай Халык Республикасы белән дәвамлы мәдәни элемтәләр булдыру максатыннан оештырылган беренче театр проекты.


Йон Фоссенең «Бер җәйге көндә» спектакле исә Кече сәхнә өчен махсус куела. Норвегиянең бу драматургы – дөньяда иң күп куелучы әдипләрнең берсе.

Гаяз Исхакыйның «Кыямәт» әсәренең дә сәхнәгә чыгуы очраклы түгел. Ул татар классик әсәрләре арасында иң яхшы сатирик комедияләренең берсе санала. Бүгенге көн өчен дә актуаль булган юк-барга ышануның акылдан өстенлек итүе темасына багышлана. Спектакльне сәхнәгә яшь режиссер Лилия Әхмәтова куя.

Күргәнебезчә, театрда безне быел тагын кызыклы премьералар, гыйбрәтле спектакльләр көтә. Алар белән якыннан танышып барырбыз дип уйлыйм.

Исегезгә төшерик: шушы көннәрдә Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасы Алтай Республикасының Горно-Алтайск шәһәрендә узган «Желанный берег» күчмә театр фестивалендә катнашты. Алар анда Н.Гогольнең «Акылдан язган кеше язмалары» спектаклен (режиссеры – Альберт Гаффаров) алып барды. Камаллылар фестивальдә сынатмау гына түгел, алтайлыларны шаккатырып кайталар. «Акылдан язган кеше язмалары» спектакленнән соң бер төркем тәнкыйтьчеләр, бертавыштан Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының югары профессиональ дәрәҗәсенә басым ясап, төп рольне (Попрощин) башкарган Рамил Вәҗиевнең уйнавына аеруча да соклану белдерәләр.

Татар театрының бер гасырдан артык тарихы бар. Халыкның талантын, рухи дөньясын, дәрәҗәсен билгели торган театр сәнгате – милләтебезнең казанышы һәм чиксез горурлыгы. Рус драматургы А.Н.Островский әйткәнчә, театр оешу – милләтнең камилләгән, өлгереп җиткәнлеген раслаучы зур тарихи вакыйга ул. Үткәнебезне барлаганда, без, халкыбызның бай мирасны, әдәбиятлы булуы белән бергә, асылда бик борынгыдан җор, тапкыр, үткен һәм шук телле, җыр-моңга, уен-тамашага һәвәслеген дә күрербез. Аулак өйләр, сабантуйлар – моның ачык мисалы.



**Илһам канатында**

**Алсу Әхәт кызы Нургатина** Аксубай районы Иске Ибрай авылында туган. Хәзерге вакытта КФУның журналистика һәм социология факультетында белем ала. Иҗат белән кызыксына, шигырьләр, хикәяләр иҗат итә. Матбугатта бик еш басылып килә.



## Ике карга

*Ашыгам,йөгерәм каядыр,*
*Утлар капкан сулышка.*
*Борылышка төште күзем,*
*Ике карга сугыша.*

*Нәфрәтләре зурдан бугай,*
*«Кар-кар»,– дип кагыналар.*
*Очына-очына,бер-берсенең*
*Күзенә ябрылалар.*

*Берсе ала,берсе кара,*
*Ни булә бу каргалар?*
*Ачуларын җиңә алмый*
*Батыштылар канга алар.*

*Берсе өстен күрә үзен,*
*Югарыдан «төкерә».*
*Икенчесе дә баш бирми,*
*Әрсез булганга күрә.*

*Борылыш – көрәш мәйданы,*
*Утлар капкан сулышка.*
*...Берсе татар,берсе урыс -*
*Ике карга сугыша.*

## Авыл кызы

*Казаннан кайтып керешкә,*
*«Тентеп» күрше-күләннәр:*
*«Син үзгәргән,Казан кызы*
*Булгансың хәзер»,– диләр.*

*Елмайсам да,тешне кысам,*
*Кызмый түзеп китәргә.*
*Кем ирере сезгә мине*
*Казан кызы итәргә?*

*Урамнарында йөрсәм дә,*
*Мин Казанда тумадым!*
*Мин авылда таптым тәмен*
*Киң колачлы дөньяның!*

*Сезнең сүзләр, беләсезме,*
*Мине шундый рәнҗетә.*
*«Авылны сагынып кайттыңмы?!»-*
*дияргә соң ни җитә?!*

*Бауман түгел – Түбән очым,*
*Кама түгел – Зур буа.*
*Борынымда башак исе,*
*Түгел «Шанель»,«Франсуа»!*

*Туган авылыма кайтам,*
*Мин төренеп язларга...*
*Авылым сукмагына тормый*
*Мең, миллион Казан да!*

*Мин Казан кызы булмадым!*
*Мин һәрчак авыл кызы!*
*Йөрәгемдә – Иске Ибрай,*
*ЗИНҺАР, аңлагыз шуны!!!*

**Студент еш әйли**

# Уку, акча һәм вакыт турында



**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

*Эш ул иң тыгыз вакытта эшләнә – бүтәннәре өелеп-бәелеп торганда. Буш вакытта киеренкелек булмый, дәрт-дәрман йоклый.*

(Ш.Галиев).

Укып бетереп, диплом алганнан соң гына эшкә урнашу модасы, миңа калса, инде күптән чыкты. Хәзерге студентларның 65%, уку белән беррәттән, эшне дә алып барырлык дәрәҗәдә. Берәүләр кыска вакыт арасыгында акча эшләү теләге белән янса, икенчеләр, киләчәктә саллырак эшкә урнашу өчен, «стаж» дигән төшенчәгә кызыгып урнаша эшкә. Дөрестән дә, яңа гына кулына диплом алган яшь белгечкә каян килсен ди стаж?! Көндезге бүлектә укыган вакытта, бик аз хезмәт хакына эшләп, укып бетергәндә стажлы булып чыкса гына инде.

Эшкә урнашуның, әлбәттә, үз плюслары һәм минуслары бар. Уңай якларына килгәндә, беренче чиратта, синең кесәңдә әтиәниең биргән акчадан тыш, үзең эшләп тапкан, кайбер кирәк-яракларыңа тотарлык кына булса да табышың була. Икенчедән, яшүсмер әзме-күпме җаваплылыкка, коллективта үз-үзен тотарга өйрәнә, «үзең эшләп ашау» дигән төшенчәнең төбенә төшә башлый. Тагын бер яхшы ягы шунда: студентның эш тәҗрибәсе барлыкка килә, университет кысаларыннан тыш яңа дуслары да арта. Вакытлыча гына урнашып торган эшне, диплом алгач, югарырак баскычта дәвам итү очраклары да җитәрлек. Бу бигрәк тә үз белгечлеге буенча эшләп йөргән студентларга хас. Плюсларга капма-каршы минуслар да бар. Көндезге бүлектә укып та, эшләп тә йөрү студентның күп энергиясен ала, шунлыктан аның ял итәргә вакыты калмый. Дөрес туклану мәсьәләсе дә үзен сиздерә. Икенчедән, студентның дәресләргә игътибары, әзерлеге кими. Аның башына: «Хи, семинарга барып, мин нәрсә алам? Ә менә эшемдә миңа акча түлиләр», – дигән уйлар килә башлый. Дәресләрне сәбәпсез калдырулар, кисәтүләр күбәя. Семестр ахырында студент имтиханны бирә алмый.

Әйе, эшкә урнаштым дип кенә йөреп булмый. Шуңа да, эш эзләгәнче, беренче чиратта, уңай һәм тискәре якларның үлчәү тәлинкәләрендә ничек тирбәлешенә карарга кирәктер. Сәламәтлек ягы да иллегә-илле булган очракта, эшкә урнашуның уңай якларын күрмим. Ә иң мөһиме, әтиәниең сиңа зур өметләр баглап йөргәндә, аларның ышанычларын акларга кирәк!

***P.S.** Ниндирәк эшләрнең аеруча да популяр икәнлеген киләсе саннарда ачыкларбыз.*

**Халәт**

# Очрашу

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче



Вакыт... Кызык төшенчә инде ул. Син өзелеп кемнедер көткәндә үтми, кадерле мизгелләр булганда, аның сине бер дә кызганып тормый узып киткәнен сизми дә каласың. Менә хәзер дә мин өзелеп-өзелеп аның килүен көтәм, ә син явызларча миңа каршы чыгасың. Аны көткәндә, бүтән эшкә кул барамыни ул?! Киендем, ясандым, бөтен кирәк-ярак та әзер... Күзге каршыннан китми йөрүемә дә күпме вакыт инде. Китап та укып карыйм, газета-журналлар да актарам, әз генә булса да башка керәме соң?.. Әле аш бүлмәсе тәрәзәсенә, әле үземнең бүлмә тәрәзәсенә йөгерәм, ә ул юк та юк. Булмас бу, киеним дә үзем каршына барыйм. Ярты юлны гына бара торсам да, очрашу аралары, юллары һәм әнә шул вакыт дигәне кыскара торыр ичмасам. Менә шулай шул ул, болай да аккан су кебек уза торган вакытны үзебезгә кирәктә ничек кенә куарга белмибез.

Урамга чыгып киттем. Ашыгам, ашкынам... Эх, бу бөкеләрне очып кына үтәр идем дә, көчемнән генә килми шул. Ничек итсәм иттем, әмма тиешле урынга килеп җиттем. Ләкин ул вакыт эчендә күңелем белән әллә ничә тапкыр очрашу мизгелен, урынын әйләнеп кайткан идем инде. Хәзер урамда көтәм. Кышкы салкын җил, буран битләрне чеметә, җылы туным эченә дә кереп чыга. Җилдавылларга гына бирешмим әле мин, очрашу шатлыгы барыннан да көчле. Телефонымдагы көйгә кушылып, кешегә сиздерми генә биим, хәрәкәт итәм, шулай салкынны җиңәм, имеш. Бер сәгать, ике сәгать... Болай булмый бит инде, тагын әзрәк торсам, кар кызына әйләнәм, ә ул юк та юк. Җылырак урынга кереп торырга кирәк, салкын тидерсәң, очрашу шатлыгының рәхәтен дә белми калырсың. Чәчәк кибетенә үтәм, ярый кибетчесе сүз әйтми тагын. Барлык чәчәкләрдә дә Аны күрәм, хыял дөньясына чумам. Шулай өченче, дүртенче, бишенче сәгать тә үтеп бара. Телефоным да чыдый алмый, соңгы авазларын суза, кибет тә бикләнде... Мин генә хисләргә бирелеп көтәм дә көтәм. Көтүләре бик авыр бит, аны көткән кеше үзе генә белә. Ничек шул хәтле соңга калырга була инде ул?! Җаваплылык дигән нәрсә бардыр бит инде? Житмәгәненә тагын урамда калдым. Суыгы да вакыт белән берлектә бит аның. Икәүләшеп җелегемә үтәләр.

Менә, ниһаять, телефоным соңгы көчен җыеп шалтырый башлады. Әллә ул инде?.. Ул! Киләм, ди бит, килеп җитәм, ди! Әнә ул, әнә, мине туган ягыма алып кайтачак машина!!! Көт, туган авылым, очрашу минутларына күп калмады-ы-ы!

# Сез исәнме? Әллә...


**Руфинә ГАБДРАХМАНОВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Исәнмесез!.. Без бу сүзне көнгә ничә тапкыр әйтәбез микән? Мөгаен, санап бетергесездер. Әдәп-әхлак та, минемчә, нәкъ шуңардан, исәнләшүдән башлана.

Авыл халкы бер-берсен яхшы белә, хәтта аларны туганнар дисәң дә ярый, шуңа күрә урамнан узганда шәхсән үзем һәр кеше белән исәнләшергә тырышам. Кечкенәдән үк канга сеңгән бу гадәттән мин тиз генә котыла алмамдыр инде. Дөресрәге, мин моны теләмим дә. Кайвакыт шәһәрдә йөргәндә дә, һәр үткән-сүткән кеше белән исәнләшәсем килә.

Җанны әрнеткәне шул: өлкәннәрнең кайберәүләре исәнләшмәүне күбрәк хуплый, ахрысы. Яннарыннан узып киткәндә, «исәнмесез»гә җавап бирмәсәләр, шулкадәр ачуым килә. Аларга шул бер сүзне әйтүе авыр микәнни соң? Әллә яшь буынга хөрмәт бетәме? Укытучылар, әти-әниләр өйрәткән әдәп дәресләре, киңәшләре – барысы да юккамыни? «Исәнме, апаем!» дигәннән телләренә бетчә чыгадыр инде!

Бер-беребезгә игътибар шулкадәр кимеде ки, хәтта үземне җәмгыятьтән аерылган итеп тоям. Сез барыгыз да исәнме соң, кешеләр?



## Хөрмәтле укучыларыбыз!

2011 елның 15 октябреннән IV Бөтенроссия «Илһамлы каләм» әдәби әсәрләр конкурсы старт ала. Биредә Татарстан Республикасында, Россиянең төрле төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче 9-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Татар телендә иҗат ителгән эшләрне (поэзия, проза, драматургия, публицистика) litconcurs@yandex.ru электрон адресына юлларга кирәк. I тур 2012 елның 15 февраленә кадәр дәвам итә. Тулырак мәгълүматны ksu.ru сайтында таба аласыз. Элемтәләр өчен телефон: 8-905-371-15-71.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 999
Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.
Газета бушлай таратыла